КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 февраль г.Казань № 85

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәр-лекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 июль, 554 нче карары белән расланган Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлек-ләрен юридик затларга, сатулар үткәр-мичә, арендага бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 июль, 554 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 сентябрь, 864 нче; 2022 ел, 12 гыйнвар, 8 нче, 2022 ел, 30 июль, 738 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны

тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның икенче абзацында «социаль-икътисадый» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3 пунктта:

2 пунктчага түбәндәге эчтәлекле «е» һәм «ж» пунктчаларын өстәргә:

«е) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 август, 1765-б номерлы боерыгы белән расланган чит дәүләтләр һәм халыкара оешмалар тарафыннан чикләү чаралары кертелгән шартларда импортны алмаштыруны тәэмин итү өчен кирәкле продукция исемлегенә керә торган продукция чыгару турында мәгълүмат, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 һәм 2023 елларда Россия Федерациясендә җир мөнәсәбәтләрен җайга салу үзенчәлекләре турында» 2022 елның 9 апрелендәге 629 номерлы карарының 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә үтенечнамә бирелгән очракта;»;

ж) Татарстан Республикасы Инвестиция советының сатулар үткәрмичә генә җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) арендага бирү турында карары турында мәгълүмат.»;

5 пунктчаның икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Хисап чорында юридик затның устав капиталы арткан очракта, соңгы хисап датасына бәйсез аудит нәтиҗәләре белән арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын раслау таләп ителми;»;

9 пунктчада:

өченче абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Хисап чорында юридик затның устав капиталы арткан очракта, соңгы хисап датасына бәйсез аудит нәтиҗәләре белән арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын раслау таләп ителми.»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик заттан индустриаль (сәнәгать) паркны төзү, һәм (яисә) үстерү, һәм (яисә) модернизацияләү, һәм (яисә) реконструкцияләү буенча проектны гамәлгә ашыру өчен үтенечнамә кергән очракта, үз акчалары булу юридик затның үз акчалары - проект инициаторы йә индустриаль (сәнәгать) паркның потенциаль резидентларының үз акчалары белән раслана. Сәнәгать (индустриаль) паркының потенциаль резидентлары крестьян-фермер хуҗалыклары яисә «Бухгалтерлык исәбе турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлеше нигезендә бухгалтерлык исәбе алып бару бурычыннан азат ителгән индивидуаль эшкуарлар булган очракта, мондый затның үз акчалары күләме үтенечнамә бирү датасына кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта әзерләнгән исәп-хисап счеты буенча банк өземтәсе белән раслана. Раслана торган үз акчаларының күләме юридик затның бизнес-планы буенча инвестицияләр күләменең кимендә 30 процентын - проект инициаторын, йә индустриаль (сәнәгать) паркның һәр потенциаль резидентының бизнес-планы буенча инвестицияләр күләменең кимендә 30 процентын, йә бирелә торган җир кишәрлегенең (җир участокларының) агымдагы кадастр бәясенең кимендә 30 процентын тәшкил итәргә тиеш.»;

14 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча әзерләнгән һәм юридик зат тарафыннан имзаланган инвестиция килешүе;»;

түбәндәге эчтәлекле 15 пунктча өстәргә:

«15) индустриаль (сәнәгать) паркны төзү, һәм (яисә) үстерү, һәм (яисә) модернизацияләү, һәм (яисә) реконструкцияләү проектын гамәлгә ашырган очракта – индустриаль (сәнәгать) паркны төзү, һәм (яисә) үстерү, һәм (яисә) модернизацияләү, һәм (яисә) реконструкцияләү проекты концепциясе, шул исәптән үз эченә ала:

индустриаль (сәнәгать) паркны төзүнең, һәм (яисә) үстерүнең, һәм (яисә) модернизацияләүнең, һәм (яисә) реконструкцияләүнең максатларын һәм бурычларын, максатка ярашлылыгын һәм алшартлары билгеләү;

сәнәгать (индустриаль) паркы идарәче компаниясе функцияләренең тасвирламасы;

резидентлар буенча индустриаль (сәнәгать) парк территориясендә агымдагы һәм планлаштырылган эшчәнлек тасвирламасы булган белешмәләр;

инвестицияләр күләме, эш урыннары саны, барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым түләүләре буенча юридик затның һәм резидентларның агымдагы һәм план күрсәткечләре;

индустриаль (сәнәгать) паркның инженерлык инфраструктурасы тасвирламасы;

индустриаль (сәнәгать) паркның транспорт белән файдалана алуын күрсәтеп, юл инфраструктурасы тасвирламасы.»;

2.5 пунктның беренче абзацында «10» саннарын «өч» сүзенә алмаштырырга;

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез була:

объектның яисә проектның Татарстан Республикасы Җир кодексына кушымтада билгеләнгән критерийларга, шулай ук критерийлар күрсәткечләренә туры килмәве;

тәкъдим ителгән документларда дөрес булмаган белешмәләрне, шул исәптән проектны гамәлгә ашырганда (объектны урнаштырганда), техник һәм финанс-икътисадый параметрларны анализлау нәтиҗәләре буенча ирешелгән критерийлар күрсәткечләре турында, күрсәтелгән күрсәткечләргә ирешү мөмкинлекләре хакында төгәл булмаган белешмәләрне ачыклау;

юридик зат тарафыннан документларны әлеге Тәртипнең 2.3 пунктындагы яисә 3.2 пунктындагы таләпләрне бозып тапшыру;

җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) проектны гамәлгә ашыруга (объектны урнаштыруга) юл куймый торган җирләр категориясенә кертү;

җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) проектны гамәлгә ашыруга (объектны урнаштыруга) юл куймый торган рөхсәт ителгән файдалану төренә кертү;

өченче зат хокукына ия җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) булу;

Татарстан Республикасы Инвестиция советының проектны гамәлгә ашыру (объектны урнаштыру) өчен Татарстан Республикасы Президенты боерыгы нигезендә үтенечнамә биргән юридик затка, җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) бирүнең максатка ярашлы булуы турында карары булмау;

проектны тормышка ашыру (объектны урнаштыру) өчен җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) мәйданының бу Тәртипнең 2.3 пунктындагы 12 һәм 13 пунктчалары нигезендә тапшырылган документларга туры килмәве, шулай ук Россия Федерациясе Җир кодексының 3916 статьясында күрсәтелгән башка нигезләр.

Үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта Агентлык күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә аны үтенечнамә биргән юридик затка җибәрә.

Үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул итү, баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булган җитешсезлекләрне, искәрмәләрне һәм башка сәбәпләрне бетергәннән соң, юридик затны әлеге Тәртип нигезендә Агентлыкка үтенеч белән кабат мөрәҗәгать итү хокукыннан мәхрүм итми.»;

2.8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Дәлилләнгән бәяләмә проектын карау һәм килештерү дәлилләнгән бәяләмә проекты килештерүгә кергән көннән алып биш эш көненнән артмаган вакытта килештерүче органнар тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

2.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.11. Килештерүче органнар тарафыннан дәлилләнгән бәяләмә проекты килештерелгән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кушымта итеп бирелгән документлар белән дәлилләнгән бәяләмә проекты кергән көннән алып биш эш көненнән артмаган чорда, кергән документларны карый. Әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында каралган үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр булган очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар документлар кире кайткан һәм үтенечнамә биргән юридик затка җибәрелгән көннән бер эш көне эчендә документларны Агентлыкка кире кайтара.»;

2.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан дәлилләнгән бәяләмә проектын килештергән очракта, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Агентлык:

инвестиция килешүенә кул куя, аны юридик затка җибәрә һәм инвестиция килешүе турында белешмәләрне Агентлык боерыгында билгеләнгән тәртиптә инвестиция килешүләре реестрына кертә;

имзаланган инвестиция килешүен һәм дәлилләнгән бәяләмәне проектны гамәлгә ашыру (объектны урнаштыру) өчен Татарстан Республикасы Президенты боерыгы проектын әзерләү максатларында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына җибәрә.»;

2.13 пунктның беренче абзацында «биш» сүзен «өч» сүзенә алмаштырырга, «Инвестиция советы беркетмәсе кушымтасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.14 пунктта «Инвестиция советы утырышы беркетмәсе һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Инвестиция килешүенә түбәндәгеләрне күздә тоткан үзгәрешләр кертелергә мөмкин:

а) җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) параметрларын үзгәртү;

б) инвестиция килешүендә күрсәтелгән юридик затның йөкләмәләрен үзгәртүне

кертеп, объект яисә проект параметрларын билгеләнгән күрсәткечләрнең 20 процентыннан күбрәгенә үзгәртү;

в) проектны гамәлгә ашыручы ( объектны урнаштыручы) юридик затны алмаштыру;

г) инвестиция килешүенең гамәлдә булу срогын бер елдан артык вакытка үзгәртү;

д) инвестиция килешүен законнар таләпләренә туры китерү;

е) юридик затның исемен һәм (яисә) адресын үзгәртү;

ж) техник характердагы төзәтмәләр кертү;

з) җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) параметрларын үзгәртмичә, алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек башкару турындагы килешүгә үзгәрешләр кертү;

и) инвестиция килешүендә күрсәтелгән юридик затның йөкләмәләрен үзгәртүне кертеп, объект яисә проект параметрларын билгеләнгән күрсәткечләрнең 20 процентыннан кимрәк үзгәртү;

к) инвестиция килешүенең гамәлдә булу срогын бер елдан кимрәк вакытка үзгәртү;

3.2 пунктта:

2 пунктчага түбәндәге эчтәлекле «д» пунктчасын өстәргә:

«д) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 август, 1765-б номерлы боерыгы белән расланган чит дәүләтләр һәм халыкара оешмалар тарафыннан чикләү чаралары кертелгән шартларда импортны алмаштыруны тәэмин итү өчен кирәкле продукция исемлегенә керә торган продукция чыгаруны үзгәртү турында мәгълүмат, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 һәм 2023 елларда Россия Федерациясендә җир мөнәсәбәтләрен җайга салу үзенчәлекләре турында» 2022 елның 9 апрелендәге 629 номерлы карарының 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә үтенечнамә бирелгән очракта;»;

5 пунктчаның икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Хисап чорында юридик затның устав капиталы арткан очракта, соңгы хисап датасына бәйсез аудит нәтиҗәләре белән арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын раслау таләп ителми;»;

9 пунктчада:

өченче абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Хисап чорында юридик затның устав капиталы арткан очракта, соңгы хисап датасына бәйсез аудит нәтиҗәләре белән арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын раслау таләп ителми.»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик заттан индустриаль (сәнәгать) паркны төзү, һәм (яисә) үстерү, һәм (яисә) модернизацияләү, һәм (яисә) реконструкцияләү буенча проектны гамәлгә ашыру өчен үтенечнамә кергән очракта, үз акчалары булу юридик затның үз акча-лары - проект инициаторы йә индустриаль (сәнәгать) паркның потенциаль резидентларының үз акчалары белән раслана. Сәнәгать (индустриаль) паркының потенциаль резидентлары крестьян-фермер хуҗалыклары яисә «Бухгалтерлык исәбе турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлеше нигезендә бухгалтерлык исәбе алып бару бурычыннан азат ителгән индивидуаль эшкуарлар булган очракта, мондый затның үз акчалары күләме

үтенечнамә бирү датасына кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта әзерләнгән исәп-хисап счеты буенча банк өземтәсе белән раслана. Раслана торган үз акчаларының күләме юридик затның бизнес-планы буенча инвестицияләр күләменең кимендә 30 процентын - проект инициаторын, йә индустриаль (сәнәгать) паркның һәр потенциаль резидентының бизнес-планы буенча инвестицияләр күләменең кимендә 30 процентын, йә бирелә торган җир кишәрлегенең (җир участокларының) агымдагы кадастр бәясенең кимендә 30 процентын тәшкил итәргә тиеш.»;

13 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) юридик зат тарафыннан имзаланган инвестиция килешүенә өстәмә килешү;»;

түбәндәге эчтәлекле 14 пунктча өстәргә:

«14) индустриаль (сәнәгать) паркны төзү, һәм (яисә) үстерү, һәм (яисә) модернизацияләү, һәм (яисә) реконструкцияләү проектын гамәлгә ашырган очракта – индустриаль (сәнәгать) паркны төзү, һәм (яисә) үстерү, һәм (яисә) модернизацияләү, һәм (яисә) реконструкцияләү проекты концепциясе, шул исәптән үз эченә ала:

индустриаль (сәнәгать) паркны төзүнең, һәм (яисә) үстерүнең, һәм (яисә) модернизацияләүнең, һәм (яисә) реконструкцияләүнең максатларын һәм бурычларын, максатка ярашлылыгын һәм алшартлары билгеләү;

сәнәгать (индустриаль) паркы идарәче компаниясе функцияләренең тасвирламасы;

резидентлар буенча индустриаль (сәнәгать) парк территориясендә агымдагы һәм планлаштырылган эшчәнлек тасвирламасы булган белешмәләр;

инвестицияләр күләме, эш урыннары саны, барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым түләүләре буенча юридик затның һәм резидентларның агымдагы һәм план күрсәткечләре;

индустриаль (сәнәгать) паркның инженерлык инфраструктурасы тасвирламасы;

индустриаль (сәнәгать) паркның транспорт белән файдалана алуын күрсәтеп, юл инфраструктурасы тасвирламасы.»;

3.3 пунктта «3.1 пунктның «д», «е» һәм «ж» пунктчалары» сүзләрен «3.1 пунктның «д» - «к» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

4.8 пунктта «һәм Инвестиция советы әгъзаларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Арендага бирелгән җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) субарендага бирүне, шулай ук җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) арендасы шартнамәсе буенча үз хокукларын һәм йөкләмләрен өченче затка аренда шартнамәсе срогы чикләрендә тапшыруны (җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) индустриаль (сәнәгать) паркны төзү, һәм (яисә) үстерү, һәм (яисә) модернизацияләү проектын гамәлгә ашыручы юридик заты тарафыннан сәнәгать (индустриаль) паркының потенциаль резидентларына субарендага бирелү очракларыннан тыш) килештерү мәсьәләләрен карап тикшерү бу Тәртипнең 2.5 – 2.15 пунктларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

әлеге Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтаның 2.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Әлеге Килешүнең шартларын үтәргә. Индустриаль (сәнәгать) паркны төзү, һәм (яисә) үстерү, һәм (яисә) модернизацияләү проектын гамәлгә ашырган очракта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 ел, 27 август, 616 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибен нигезендә аккредитация үтәргә.»;

Инвестиция килешүенә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Инвестиция килешүенә
1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 3 февраль, 85 нче
карары редакциясендә)

Форма

Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектны урнаштыруның яисә масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыруның план күрсәткечләре

______________________________________________
(объект (проект) исеме)

| Хисап параметрының исеме | Параметрның әһәмияте | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 20__ ел | | | | 20__ ел | | | | 20__ ел | | | | 20__ ел | | | | 20__ ел | | | | 20__ ел | | | |
| | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 |
| Инвестицияләр күләме (объектны урнаштыра (проектны гамәлгә ашыра) башлаганнан бирле, мең сум | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Эш урыннары булдыру (объектны урнаштыра (проектны гамәлгә ашыра) башлаганнан бирле), берәмлек (булган очракта) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы бюджетына салым кертемнәре, мең сум | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Резидентлар саны, берәмлек (индустриаль (сәнәгать) паркны төзү, һәм (яисә) үстерү, һәм (яисә) модернизацияләү, һәм (яисә) реконструкцияләү проектын гамәлгә ашырган очракта) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |